Р.З. Хайдарова, Г.М. Ахметзянова,
Л.А. Гиниятуллина

# ТАТАР ТЕЛЕ

## Укытучылар өчен методик кулланма



**5**

«Татармультфильм»

Р. З. Хәйдәрова, Г. М. Әхмәтҗанова,
Л. Ә. Гыйниятуллина

# ТАТАР ТЕЛЕ

## 5 нче сыйныф

**Укытучылар өчен методик кулланма**

*Татарстан Республикасы
Мәгариф һәм фән министрлыгы
тарафыннан тәкъдим ителә*

Казан
2025

УДК 81.432.3-99(=411.2)я72
ББК 811.512.145(073.5)
Х18

Фәнни редакторы
**Р. З. Хәйдәрова,**
педагогика фәннәре кандидаты, доцент

*Охраняется действующим законодательством об авторских и смежных правах (Гражданский кодекс РФ, ч. 4, гл. 70). Воспроизведение всего издания или его части на любых видах носителей запрещается без письменного разрешения издательства.*

**Хайдарова, Р. З. и др.**
Х18 Государственный (татарский) язык Республики Татарстан: Татар теле. 5 класс: методическое пособие для учителя к учебнику для общеобразовательных организаций основного общего образования (для обучающихся, не владеющих татарским языком) / Р. З. Хайдарова, Г. М. Ахметзянова, Л. А. Гиниятуллина. – Казань: Татармультфильм, 2025. – 48 с.

ISBN 978-5-906508-50-8

УДК 81.432.3-99(=411.2)я72
ББК 811.512.145(073.5)

ISBN 978-5-906508-50-8

© «Татармультфильм» нәшрияты, 2025
© Хәйдәрова Р. З., Әхмәтҗанова Г. М., Гыйниятуллина Л. Ә., 2025

**5 нче сыйныфта «Татарстан Республикасы дәүләт (татар) теле» фәнен укыту өчен төзелгән «Татар теле» укыту-методик комплекты белән эшләү үзенчәлекләре**

Федераль дәүләт стандартларында белем бирү системасының төп үсеш юнәлеше – **системалы-эшчәнлекле юнәлеш (системно-деятельностный подход)**, ә системаны барлыкка китерә торган төп компонент – **нәтиҗә: шәхси, метапредмет, предмет нәтиҗәләре** дип билгеләнелә. Стандартларда күрсәтелгән бу концептуаль методологик күрсәтмә рус телле балаларга татар теле укыту системасын оештыруның да нигезе булып тора.

Рус телендә сөйләшүче укучыларга татар телен дәүләт теле буларак укытуның төп максаты – укучыларның рухи һәм әхлакый үсешен тәэмин итү, аларның күпмилләтле җәмгыятьтә милләтара мөнәсәбәт культурасын формалаштыру, башка халыкларга карата хөрмәт хисе, мәдәниара диалогка осталык кебек универсаль күнекмәләр булдыру, татар телен дәүләт теле буларак укыту телне **аралашу** чарасы буларак үзләштерүне тәэмин итү, көндәлек тормышта, полиэтник җәмгыятьтә **үзара аңлашу** һәм **хезмәттәшлек** итү күнекмәләрен формалаштыру. Шулай ук укучыларның фикер йөртү, интеллектуаль һәм иҗади сәләтләрен үстерү; уку эшчәнлеген оештыруның нигезе булган универсаль уку гамәлләрен формалаштыру, аларны мөстәкыйль уку эшчәнлегенә әзерләү.

Татарстан Республикасы мәктәпләре өчен төп гомуми белем бирү баскычында татар теле фәнен укытуга **372 сәгать** вакыт бирелә. Базис укыту планында 5 нче сыйныфта атнага 3 сәгать исәбеннән **102 сәгать** каралган.

Бишенче сыйныфта укучы рус телле балаларга тәкъдим ителгән укыту-методик комплекты (УМК) түбәндәге компонентлардан тора:

1. Дәреслек.
2. Укытучы өчен методик ярдәмлек:
– календарь-тематик план;
– ишетеп аңлау күнегүләре;
– контроль-үлчәм материаллары.

УМКга эчтәлек сайлау Россия мәгариф министрлыгының 18.05.2023 елгы 372 номерлы «Төп гомуми белем бирүнең федераль белем бирү программасын раслау турында»гы боерыгына (теркәлү вакыты: 12.07.2023 ел, №74229) һәм тел өйрәтү процессында методик стандарт итеп кабул ителгән коммуникатив технология принципларына нигезләнде.

**Телгә аралашу аша өйрәтү принцибының** нигезендә дәреслеккә сайланган эчтәлекнең укучыларның яшь үзенчәлекләренә, теләк-омтылышларына, аралашу ихтыяҗларына туры килүе мәҗбүр. Шушы психологик, педагогик таләпләр үтәлгәндә генә, уку материалын кабул итүдә укучыда актив фикри эшчәнлек башлана, үз фикерен әйтү теләге туа, укучы табигый рәвештә уку эшчәнлегенә тартыла. Ягъни укучыда укытучы кушканга түгел, ә үз теләге, үз ихтыяры белән табигый рәвештә сөйләм эшчәнлеге башлана.

Дәреслеккә түбәндәге аралашу темалары кертелде: «Без мәктәптә» («Без дәрестә»), «Мин – өйдә булышчы» («Минем гаиләм»), «Дуслар белән күңелле», «Безнең бәйрәмнәр» («Гаилә бәйрәмнәре, традицияләр», «Бүләкләр, котлаулар», «Кунакта», «Сабантуй бәйрәме»), «Татарстан – туган җирем» («Туган илем»), «Туган ягым табигате» («Хайваннар дөньясында»), «Без спорт яратабыз» («Сәламәтлек һәм спорт», «Яраткан шөгыльләр») «Без юлда» («Транспортта»). Тематик планнарда темаларның эчтәлеге киңәйтелеп, федераль эш программасына тәңгәллеге күрсәтеп барылды.

Федераль эш программасына нигезләнеп, дәреслеккә грамматик материал түбәндәгечә кертелде:

– исемнәрнең берлек һәм күплек санында килеш белән төрләнеше;

– исемнәрнең берлек һәм күплек санда тартым белән төрләнеше;

– вакыт (былтыр, быел, иртән, көндез, кичен), охшату-чагыштыру (татарча, русча, инглизчә) рәвешләре;

– берлек һәм күплек сандагы II зат боерык фигыльнең барлык һәм юклык формалары: бар! – барыгыз! (ба́рма! – ба́рмагыз!);

– берлек һәм күплек сандагы I, II, III зат билгеле үткән заман хикәя фигыльнең барлык һәм юклык формалары;

– III зат билгесез үткән заман хикәя фигыльнең берлек сан формасы;

– фигыльнең инфинитив формасын модаль сүзләр (*кирәк, кирәкми, ярый, ярамый*) белән сөйләмдә куллану;

– *өчен, шикелле* бәйлекләрен сөйләмдә куллану;

– *янында, өстендә, астында, эчендә* бәйлек сүзләре;

– теркәгечләр;

– *минемчә, синеңчә* кереш сүзләрен сөйләмдә куллану.

Моннан тыш, алдагы сыйныфларда өйрәнелгән лексик-грамматик материал даими рәвештә кабатланып барылды.

Рус телле балаларны татар сөйләменә коммуникатив технология нигезендә өйрәтү **дәреслекләренең төзелеше цикллылыкка** корылган.

**Цикл – уку материалын диалогик, монологик, ягъни мөстәкыйль сөйләм дәрәҗәсенә җиткерү өчен кирәк булган дәресләр.** Ягъни өйрәнелгән лексик-грамматик материал тану дәрәҗәсендә генә калмыйча, сөйләмдә мөстәкыйль кулланылу дәрәҗәсенә җиткерелергә тиеш. Дәрес тибы буенча бу дәресләр текст алды дәресләре: **лексик күнекмәләр формалаштыру** (ЛКФ) һәм **грамматик күнекмәләр формалаштыру** (ГКФ); текст өстендә эш дәресләре: **лексик күнекмәләрне камилләштерү дәресе** (ЛКК), **грамматик күнекмәләрне камилләштерү дәресе** (ГКК), **диалогик/монологик сөйләм дәресләре** (Д/МС) дип атала. Бу дәресләр циклында өйрәнелгән лексика һәм грамматика турыдан-туры текстта кабатлана, төрле бәйләнешләргә керә, ягъни лингвистик материалны сөйләмдә куллану камилләшә. Тексттан соң булган этапта текст эчтәлеге буенча диалогик-монологик сөйләмгә чыгу дәресләре оештырыла, укучылар материал эчтәлеге буенча спонтан сөйләм – **татарча аралашу этабына чыгалар.**

Психологлар, методистлар фикеренчә, материалны кат-кат кабатлап, ятлап өйрәнүгә караганда, аралашу ситуацияләрендә сөйләм бурычына тәңгәл килгән лексик-грамматик материалны укучыларның мөстәкыйль комбинацияләп сөйләшүе – тел өйрәнүдә күп мәртәбә нәтиҗәлерәк алым. Шуңа күрә дәреслектә эчтәлекне мөстәкыйль сөйләмгә җиткерү өчен сөйләми (речевые) күнегүләр: диалоглар, ситуатив күнегүләр, иҗади биремнәр еш кулланылды. Дәреслектәге күнегүләрдән тыш, укытучылар түбәндәге методик ярдәмлеккә мөрәҗәгать итә алалар: «Мин татарча сөйләшәм. Я говорю по-татарски». Сборник ситуативных упражнений для русскоязычных учащихся. Авт.: Р. З. Хайдарова, Г. М. Ахметзянова, Л. А. Гиниятуллина. Наб. Челны, 2019.

Телне аралашу ситуацияләренә бәйләп өйрәнгәндә, укучылар тел өйрәнүнең практик әһәмиятен шундук тоялар, эмоциональ күтәренкелек туа һәм тел өйрәнү процессының мотивлашкан булуы тәэмин ителә.

Укучыларның сөйләми активлыгын булдыруда шулай ук уку эшчәнлеген оештыруның **эш режимнарын** дөрес оештыру да бик мөһим. Дәреслектә федераль дәүләт стандартларының таләпләренә туры килгән **парларда, төркемнәрдә, индивидуаль эшләү өчен биремнәр** һәм **иҗади** биремнәр **киң урын алды**. Алар дәреслектә аерым шартлы билгеләр белән күрсәтелә барды.

Укытучы өчен **методик ярдәмлеккә** ишетеп аңлау күнегүләре (аудирование), федераль эш программасы нигезендә төзелгән календарь-тематик план, һәр тема буенча контроль һәм үзконтроль материаллары кертелде.

1) Ишетеп аңлау күнегүләре – һәр дәрестә, дәреснең төрле этапларында кулланылырга тиешле сөйләм эшчәнлеге. Ишетеп аңлау күнегүләренә таләпләр федераль эш программасында киң яктыртылу сәбәпле, методик ярдәмлектә дәрес темалары буенча күнегүләрнең үзләрен бирү белән чикләнелде.

2) Тәкъдим ителгән **тематик план** ел дәвамында өйрәнәсе материалның дәресләргә бүленешен күрсәтә. Һәр дәреснең коммуникатив максаты тематик планда аерым графада күрсәтелә барды, шуңа күрә дәрес планы, дәреснең структур этапларын планлаштырганда, аңа игътибар итү аеруча мөһим.

Федераль эш программасы бүлекләренең эчтәлеге тулысынча дәреслеккә һәм тематик планга салынды, аның үтәлеше күрсәтелә барды. Федераль эш программасы бүлекләренең эзлеклелеге белән дәреслектәге, тематик пландагы эчтәлек бирелеше эзлеклелеге тәңгәл килмәгән очракта да, **дәреслектәге һәм тематик пландагы дәресләр бирелешенең эзлеклелеген алыштырырга тәкъдим ителми**, чөнки федераль эш программасы нигезендә төзелгән дәреслек эчтәлегенең үзара бәйләнеше, системалылыгы бозыла.

3) Укыту процессының уңышлылыгына тәэсир итә торган әһәмиятле факторларның берсе – ул укучыларның белемен **контрольгә** алу. Билгеле булганча, **контроль** укыту барышын көйли, ягъни, контрольгә карап, укытучы үз эшчәнлеген оештыра. Методика фәне билгеләгәнчә, укучыларның ятлаганны сөйли белүләре, аерым сүзләрне, җөмләләрне тәрҗемә итә белүләре, яисә грамматик категорияләрне аңлый алулары гына **контроль объекты** була алмый. Укучының, өйрәнелгән лексиканы һәм грамматиканы кулланып, программа темалары буенча **мөстәкыйль аралаша алуы** контрольнең **төп объекты** булып тора. Календарь-тематик планның коммуникатив максат графасында дәресләр өчен күрсәтелгән **предмет нәтиҗәләре, ягъни тема буенча сөйләшә белү күләме** укучыларның белем дәрәҗәләрен контрольгә һәм үзконтрольгә алуның да эчтәлеген тәшкил итә ала.

## 5 нче сыйныфта рус төркемнәрендә татар теле укытуның тематик планы

| № | Дәрес темасы | Дәреснең коммуникатив максаты |
|---|---|---|
| **Без мәктәптә (22 сәгать)**<br>**II. Мир вокруг меня** | | |
| 1–2 | Яңа уку елы котлы булсын!<br>Исәнләшү кагыйдәләре | Өлкәннәр һәм кечкенәләр белән исәнләшү, саубуллашу кагыйдәләре. Бәйрәм белән котлый, бер-береңә комплимент әйтә белү |
| 3 | Исемнәрнең берлек санда тартым белән төрләнеше | Уку-язу әсбапларының барлыгын, юклыгын, кайда икәнлекләрен әйтә белү. Үзеңә уку-язу әсбапларын сорый белү |
| 4 | Кая? Кайда? Кайдан? сораулары | Кая? Кайда? Кайдан? сорауларын сөйләмдә куллана белү. Үзеңә уку-язу әсбапларын сорый, кирәклеген әйтә, иптәшеңә, тәкъдим итә белү |
| 5–6 | Мәктәптә белем бәйрәме.<br>Россиянең, Татарстанның дәүләт гимннары | Мәктәптә белем бәйрәме турында сөйли белү. Россиянең, Татарстанның дәүләт гимны турында сөйләшү |
| 7–8 | Исемнәргә кушымчалар ялгану тәртибе.<br>*Минем мәктәбемдә* төзелмәсе | Исемнәргә кушымчалар ялгану тәртибен аңлау. *Минем дәфтәремдә* төзелмәсен сөйләмдә дөрес куллану. Контроль эштә хата барлыгын, хата юклыгын әйтә белү |
| 9 | Исемнәрнең күплек санда тартым белән төрләнеше | Исемнәрнең күплек санда тартым белән төрләнешен сөйләмдә дөрес куллану |
| 10–11 | Боерык фигыльнең зат-сан белән төрләнеше | Боерык фигыльне II зат берлек һәм күплек саннарда сөйләмдә куллана белү |
| 12 | Әдәпле сөйләшәбез | *Бир әле, бирче, бирегез әле* төзелмәләрен сөйләмдә куллану |
| 13–14 | Хәзерге заман хикәя фигыльләрнең барлык формасында зат-сан белән төрләнеше.<br>«Без дәрестә» | Хәзерге заман хикәя фигыльне барлык формасында сөйләмдә куллану |
| 15–16 | Хәзерге заман хикәя фигыльләрнең юклык формасында зат-сан белән төрләнеше | Хәзерге заман хикәя фигыльне юклык формасында сөйләмдә куллану |
| 17–18 | Билгеле үткән заман хикәя фигыль.<br>«Олегның нигә кәефе юк?» тексты буенча лексик-грамматик материал | Хикәяне сәнгатьле уку, эчтәлекне сөйли белү |

| | | |
|---|---|---|
| 19–20 | «Олегның нигә кәефе юк?», «Без хикәя язабыз» | Өй эше эшләү турында сөйләшү. Олегка бәя бирә белү. Уенга чакыра белү |
| 21–22 | Сан төркемчәләре. *«Сан + исем»* төзелмәсе | Дистәләр һәм йөзләр эчендәге саннарны сөйләмдә куллана белү. Дәресләр расписаниесен әйтә белү. Үзе турында саннар кулланып, мәгълүмат бирә белү |
| **Мин – өйдә булышчы (19 сәгать)<br>I. Мир моего «Я»** | | |
| 23–24 | Гаилә әгъзалары. *Сатучы булып эшли* төзелмәсе | Гаилә әгъзаларының һөнәрләре, аларның кем булып эшләүләре турында әйтә белү |
| 25–26 | Сәгать ничә?<br>«Минем көндәлек режимым».<br>Вакыт рәвешләре | Көндәлек режимны сөйли белү.<br>Вакытны сорый белү |
| 27–29 | Билгеле үткән заман хикәя фигыльнең I, II, III зат формалары. «Мин – өйдә булышчы» | Билгеле үткән заман хикәя фигыльнең барлык, юклык формаларын кулланып, өй хезмәте турында сөйләшү |
| 30–31 | Илнур белән Рәсимнең иртәнге режимы | Хикәяне сәнгатьле уку, эчтәлекне сөйли белү |
| 32–33 | Илнур, Рәсим образларына чагыштырма характеристика | Илнур, Рәсим образларына чагыштырма характеристика бирә белү.<br>Бер-береңә киңәшләр бирә белү |
| 34–35 | *Инфинитив + кирәк, телим, ярый, ярамый* төзелмәсе.<br>Без – өйдә булышчы | Эш эшләргә киңәш бирә белү, өй эшләрен эшләргә кирәклеген әйтә белү.<br>Өй хезмәте турында сөйләшү |
| 36–37 | «Без нинди булышчылар?», «Мин энемне мактыйм» | Яхшы эшләр өчен бер-береңне мактый белү.<br>Өй хезмәтенә карап, кешегә бәя бирә белү |
| 38–39 | *Өчен*, *шикелле, кебек* бәйлекләре.<br>Ю. Ермолаевның «Ике пирожный» хикәясендәге лексик-грамматик материал | Предметның кем өчен икәнен әйтә белү.<br>Хикәяне сәнгатьле уку, эчтәлекне сөйли белү.<br>Булышырга чакыра белү; ничек булышканны әйтә белү |
| 40–41 | Ю. Ермолаевның «Ике пирожный» хикәясе | Өй хезмәтендә катнашуга карап, кешегә бәя бирә белү. Кереш сүзләр кулланып, образларга бәя бирү.<br>Яңа хикәя язу |
| **Дуслар белән күңелле (8 сәгать)<br>II. Мир вокруг меня** | | |
| 42–43 | «Минем дусларым» темасы буенча лексик-грамматик материал. «Минем дусларым бар» | Дусларың турында дәреслектәге план буенча сөйли белү, дуслашырга тәкъдим итә белү |

| | | |
|---|---|---|
| 44 | Сыйфат дәрәҗәләренең сөйләмдә кулланылышы | Сыйфат дәрәҗәләрен сөйләмдә куллану |
| 45–46 | «Язгы каникул» хикәясендәге лексик-грамматик материал.<br>«Язгы каникул» хикәясе | Хикәяне сәнгатьле уку.<br>Киңәш һәм боеруны белдерү формаларын аера белү |
| 47 | Берлек һәм күплек сандагы II зат боерык фигыльнең барлык һәм юклык формалары.<br>Боеруны һәм үтенечне белдерү.<br>«Без матур сөйләшәбез» | Хикәянең эчтәлеген сөйли белү.<br>Киңәш һәм боеруны белдерү формаларын сөйләмдә куллана белү |
| 48 | «Дусларга ни өчен күңелсез?»<br>Без хикәя язабыз | *Чөнки* теркәгечен кулланып, дусларга ни өчен күңелсез булуы турында сөйләшә белү.<br>Яңа хикәя язу |
| **Безнең бәйрәмнәр (19 сәгать)<br>I. Мир моего «Я»** | | |
| 49–50 | «Яңа ел – күңелле бәйрәм» тексты | Яңа ел бәйрәменә әзерләнү турында, бәйрәмне кайда каршылавың, бәйрәмдә катнашуың турында сөйли белү |
| 51 | Яңа елны ничек каршылыйлар? | Яңа елны ничек каршылау турында сөйләшү. Бәйрәм белән котлый белү |
| 52–53 | 8 нче Март – әниләр бәйрәме | 8 нче Март бәйрәменә бүләкләр алу турында сөйләшү. Бәйрәм белән котлый белү |
| 54–55 | Исемнәрнең килеш белән төрләнеше.<br>Туган көн – иң күңелле бәйрәм | Туган көнгә бүләкләр алу турында сөйләшү. Туган көн белән котлый белү |
| 56 | Ш. Галиевнең «Кунаклар» шигыре | Өстәл әзерләү турында сөйли белү; шигырьне сәнгатьле укый белү |
| 57–58 | Мин туган көнгә чакырам | Телефоннан әдәпле сөйләшә белү.<br>Туган көнгә әдәпле чакыра белү |
| 59–60 | Без туган көндә | Туган көн үткәрү турында сөйләшү |
| 61–63 | Р. Вәлиеваның «Туган көндә» хикәясе.<br>*Минемчә, синеңчә* кереш сүзләре | Геройга характеристика бирә белү, хикәяне үзгәртеп төзи, төзегәнне сөйли белү |
| 64–65 | Бәйлек сүзләр.<br>«Табын янында» хикәясе | Бәйлек сүзләрне сөйләмдә куллана белү.<br>Хикәяне сәнгатьле уку |
| 66 | «Табын янында» тексты.<br>Без хикәя язабыз | Сашаның табын янында үз-үзен тотышын сөйли, тәнкыйть итә, аңа киңәшләр бирә белү. Хикәяне үзгәртеп язу |

| | | |
|---|---|---|
| **Татарстан – туган җирем (4 сәгать)**<br>**IV. Моя Родина** | | |
| 67–68 | Туган җирем – Татарстан.<br>Охшату-чагыштыру рәвешләре | Татарстан Республикасының дәүләт атрибутикасы турында сөйли белү. Шәһәрләре турында кыскача белешмә бирә, Татарстанда яшәүче халыклар дуслыгы турында сөйли белү |
| 69–71 | Казан – Татарстанның башкаласы.<br>*Казан Кремле* төзелмәсе | Татарстанның башкаласы Казан турында текст эчтәлеге буенча сөйли белү |
| **Туган як табигате (14 сәгать)**<br>**IV. Моя Родина** | | |
| 72–74 | Татарстан табигате.<br>Теркәгечләрнең сөйләмдә кулланылышы | Татарстан табигате турында текстта бирелгән мәгълүматны кулланып сөйли, дустыңнан сорый белү |
| 75–76 | Хайваннар һәм кошлар | Татарстанда нинди хайваннар, кошлар яшәгәнлеге турында сөйләшә белү, әйтә белү |
| 77–78 | «Керпе» тексты | Текстны сәнгатьле уку, эчтәлекне сөйли белү |
| 79–80 | Г. Тукайның «Ташбака белән Куян» мәсәле | Мәсәлне сәнгатьле уку, эчтәлеген сөйли белү |
| 81–82 | Дүртаяклы дусларыбыз | Этләрне сурәтли, гадәтләре турында сөйли белү |
| 83–84 | Дүртаяклы дусларыбызның кушаматлары, гадәтләре | Этләрне сурәтли, гадәтләре турында сөйли белү |
| 85 | Минем этем | Этләрне сурәтли, нинди командалар үтәве, гадәте турында сөйли белү |
| **Без спорт яратабыз (6 сәгать)**<br>**III. Мир моих увлечений** | | |
| 86–88 | Спорт төрләре.<br>Мин нинди спорт төре белән шөгыльләнәм? | Нинди спорт төрләре яратканны сорый, әйтә белү. Спорт уеннары турында сөйләшә белү |
| 89–90 | «Мин авырыйм»,<br>«Мин табибта» | Тән әгъзалары исемнәрен, кайсы җиреңнең авыртканын табибка әйтә, иптәшеңнең кайсы җире авыртканын сорый белү |
| 91–92 | «Сәламәт булу өчен нишләргә кирәк?»<br>*Инфинитив + кирәк (кирәкми)* төзелмәсе | Сәламәт булу өчен нишләргә кирәклеге турында бер-береңә киңәшләр бирә белү |
| **Без юлда (10 сәгать)**<br>**II. Мир вокруг меня** | | |
| 93–95 | Светофор – минем дустым | Шигырьне сәнгатьле уку, машина маркаларын әйтә белү. Юл йөрү кагыйдәләрен сөйли белү |
| 96–97 | *Аша, аркылы* бәйлекләре | Диалогны үзгәртеп төзү, киңәшләр бирә белү |
| 98–99 | Юл йөрү билгеләре | Юл йөрү билгеләрен әйтә белү. Юл йөрү кагыйдәләрен сөйли белү |
| 100–102 | Сабантуй бәйрәме.<br>Сабантуй уеннары | Сабантуйга баруың, бәйрәмдә төрле уеннарда катнашуың турында сөйли белү |

## Ишетеп аңлау күнегүләре

### Без мәктәптә

### 1–4 нче дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова приветствия и прощания.**

Исәнмесез, Зифа апа! Сәлам, Гүзәл! Уңышлар телим. Хушыгыз, Илдар абый! Хуш, Мансур! Яхшы кәеф телим. Саумы, Гүзәл! Сәламәтлек телим. Сау булыгыз, Алсу апа. Сау бул, Оксана.

**2. Прослушайте и укажите слова со звуком [қ].**

Белем көне, котлыйм, сәламәтлек, укытучы, күңелле, бүләк.

**3. Прослушайте и повторите эти слова, добавляя к ним местоимения *минем*, *синең*, *аның*.**

Сумкам, карандашың, көндәлеге, журналы, күлмәгең, укытучым, китабың, дәфтәрем.

**4. Прослушайте и скажите, какие из этих предметов находятся на учительском столе.**

Китап, парта, дәфтәр, көндәлек, акбур, каләм, урындык, журнал, гөл, такта, чүпрәк, шкаф, карандаш, каләм.

**5. Прослушайте и скажите эти слова во множественном числе.**

Күлмәк, укучы, укытучы, чәчәк, кеше, дәфтәр, карандаш, бетергеч, көндәлек, китап.

**6. Прослушайте и укажите, что добавлено во втором предложении каждой пары.**

1) Сине котлыйм. Сине бәйрәм белән котлыйм.
2) Сиңа бирәм. Сиңа чәчәкләр бирәм.
3) Күлмәгең матур. Синең күлмәгең бик матур.

## 5–6 нчы дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова со звуками [қ], [к].**

Күңелле, ел, көн, бәйрәм, укытучы, чәчәк, котлый, дәрес.

**2. Прослушайте и повторите эти слова, добавляя к каждому из них местоимения *минем, синең, аның*.**

Мәктәп, чәчәк, укытучы, китап, ручка.

**3. Прослушайте и укажите лишнее слово в логическом ряду.**

Дүшәмбе, сишәмбе, чәршәмбе, пәнҗешәмбе, сентябрь, шимбә, якшәмбе.

**4. Прослушайте и укажите, что добавлено во втором предложении каждой пары.**

1) Көн матур. Көн гаҗәп матур.
2) Көн җылы. Көн искиткеч җылы.
3) Музыка уйный. Күңелле музыка уйный.

**5. Прослушайте и закончите предложения.**

1) Балалар мәктәпкә … .
2) Мәктәптә бүген ... .
3) Мәктәптә күңелле музыка ... .
4) Укучылар укытучыларга чәчәк бәйләмнәре ... .

**6. Прослушайте и измените данные слова по образцу.**

| | |
|---|---|
| бер – беренче | биш – ... |
| ике – ... | алты – ... |
| өч – ... | җиде – ... |
| дүрт – ... | сигез – ... |

**7. Назовите слова, выражающие действие.**

Матур, башлана, киенә, мәктәп, бүләк итә, котлый, белә.

## 7–9 нчы дәресләр

**1. Прослушайте и укажите двусложные слова.**

Дәфтәр, дәрес, дәреслек, хата, урам, китап, тарак, көндәлек.

**2. Прослушайте и укажите слово, логически не связанное с другими.**

Китабым, карандашым, бетергечем, көндәлегең, дәфтәрем, каләмем.

**3. Прослушайте и повторите данные слова, добавляя к каждому из них местоимения *минем, синең, аның.***

Дәреслек, китап, күлмәк, көндәлек, бакча, урам.

**4. Прослушайте и укажите, что изменено во втором предложении каждой пары.**

1) Минем дәреслегем яңа. Минем дәреслегем чиста.
2) Минем язма эшем хаталы. Минем язма эшем хатасыз.
3) Миңа шакмаклы дәфтәр кирәк. Миңа буйлы дәфтәр кирәк.

**5. Прослушайте и перескажите содержание диалога.**

– Айдар, бакчагыз еракмы?
– Юк, ерак түгел. Ә сезнең бакчагыз бармы, Олег?
– Бар.
– Кайда?
– Бакчабыз шәһәр янында.

## 10–12 нче дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова с мягкими гласными звуками.**

Кил, бар, сана, чиш, эшлә, тыңла, куй, яз, яса, утыр, сал, укы, кара, кер, чык, кис.

**2. Прослушайте и укажите глаголы повелительного наклонения.**

Ала, сал, укый, язышыз, бир, бүләк итегез, өйрәнә, укы, тыңлый, салма, бара, котлый, куя, чиш, сөйләшмә.

**3. Прослушайте и назовите слова, выражающие действие в движениях.**

Яз, бас, йөгер, сикер, кис, исәнләш, сөрт, утыр, укы.

**4. Прослушайте и укажите, что добавлено во втором предложении каждой пары.**

1) Дәфтәр ал. Сумкадан дәфтәр ал.
2) Укытучыны тыңлагыз. Дәрестә укытучыны тыңлагыз.
3) Чәчәк бүләк ит. Укытучыга чәчәк бүләк ит.

**5. Прослушайте и закончите предложения, употребляя повелительную форму глагола.**

1) Сумкадан китапны ... .
2) Китапны партага ... .
3) Дәфтәреңне ... .
4) Чүпрәк ... .
5) Тактаны ... .

**6. Прослушайте данные просьбы-предложения и ответьте на них положительно.**

– Оля, базарга бар әле.
– Никита, каләм бир әле.
– Дамир, сумканы ал әле.
– Надя, китапны өстәлгә куй әле.

## 13–14 нче дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова мягкого произношения.**

Юа, сибә, килә, кайта, эшли, беләсез, сөйли, уйный, утыра, чишә, булыша.

**2. Прослушайте и укажите глаголы множественного числа, определите их лица.**

Эшли, кайтасың, беләсез, сөйлим, сөйлибез, килә, киләләр, булышабыз.

**3. Прослушайте и укажите, что изменено во втором предложении каждой пары.**

1) Контроль эш була. Татар теленнән контроль эш була.
2) Диктант язабыз. Рус теленнән диктант язабыз.
3) Мәсьәлә чишәләр. Математикадан мәсьәлә чишәләр.

**4. Прослушайте и повторите глаголы, добавляя к каждому из них местоимения *без, сез, алар.***

Укый, яза, эшли, килә, китә, уйный, кайта, утыра, белә, сөйли.

**15–16 нчы дәресләр**

**1. Прослушайте и укажите слова со звуком [қ].**

Бармый, килми, калмый, чыкмый, керми, куймый, юмый.

**2. Прослушайте и укажите лишнее слово в грамматическом ряду.**

Бармый, килми, калмый, чыкмый, керә, куймый, юмый.

**3. Прослушайте и укажите, что изменено во втором предложении каждой пары.**

1) Коля бармый. Коля мәктәпкә бармый.
2) Саша укымый. Саша китап укымый.
3) Петя телевизор карамый. Петя кич белән телевизор карамый.

**4. Прослушайте и повторите глаголы, добавляя к каждому из них местоимения *без, сез, алар.***

Укымый, язмый, эшләми, килми, китми, уйнамый, кайтмый, утырмый, белми, сөйләми.

**17–20 нче дәресләр**

**1. Прослушайте и выберите глаголы, к которым в прошедшем времени прибавляются окончания *-ды/-де.***

Ала, китә, уйный, карый, керә, сөртә, уйлый, сорый, оныта, бирә.

**2. Прослушайте и укажите, что изменено во втором предложении каждой пары.**

1) Мин укыйм. Мин тырышып укыйм.
2) Без уйнарга чыктык. Без урамга уйнарга чыктык.
3) Мин шигырь ятлыйм. Мин мисал чишәм.

**3. Прослушайте и укажите слова, отвечающие на вопрос *кайдан?***

Өйдән, урамда, мәктәпкә, бакчадан, эштән, өйгә, урамнан, урманда.

**4. Прослушайте и укажите слово со звуком [ә].**

*Кәеф,* өй эше, башта, озак, кызыклы, сәгать, чирек, мөстәкыйль эш.

**5. Прослушайте и укажите словосочетание, логически не связанное с другими.**

Контроль эш, мөстәкыйль эш, язма эш, чирек азагы.

**6. Прослушайте и закончите предложения.**

1) Бүген Олегның кәефе … .
2) Олег өй эшен … .
3) Олег контроль эшне начар ... .
4) Олег урамда озак … .
5) Иртәгә мөстәкыйль … .

**7. Прослушайте диалог и скажите, сколько в нём вопросительных предложений.**

– Сезнең бүген ничә дәрес?
– Биш.
– Беренче дәрес нинди?
– Математика.
– Ә икенче дәрес?
– Икенче дәрес – татар теле.
– Син дәрескә әзерме?
– Әйе, мин өй эшен яхшы эшләдем.
– Математикадан ике мәсьәләне дә чиштеңме?
– Әйе, чиштем.

## 21–22 нче дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова с мягкими гласными.**

Яхшы, дәрес, кәеф, иптәш, көчле, китап, ихтыяр, дәфтәр.

**2. Прослушайте и измените данные слова по образцу.**

| | |
|---|---|
| бер – беренче | биш – ... |
| ике – ... | алты – ... |
| өч – ... | җиде – ... |
| дүрт – ... | сигез – ... |

**3. Прослушайте и скажите, какие слова пропущены в логическом ряду.**

Беренче, ... , өченче, дүртенче, ... , ... , җиденче, ... , тугызынчы, ... .

**4. Прослушайте и укажите слова, обозначающие учебные предметы.**

Математика, өй эше, рус теле, әдәбият, һәрвакыт, чит тел, татар теле.

**5. Прослушайте и скажите, какие числа пропущены в логическом ряду.**

Берәү, икәү, ... , дүртәү, бишәү, ... , җидәү, ... , ... , унау.

**6. Прослушайте и укажите лишнее слово в грамматическом ряду.**

Беренче, икенче, өченче, дүртенче, бишенче, алты, алтынчы, җиденче, сигезенче.

**7. Прослушайте и укажите слово, грамматически не связанное с другими.**

Юды, язды, тотты, җыйды, ясый, килде, әзерләде, керде.

## Мин – өйдә булышчы

### 23–24 нче дәресләр

**1. Прослушайте и повторите данные слова, добавляя к каждому из них местоимения *минем, синең, аның.***

Әти, әни, әби, бабай.

**2. Прослушайте и укажите слова с твёрдыми гласными звуками.**

Сатучы, тегүче, балыкчы, укытучы, бакчачы, тәрбияче, очучы.

**3. Прослушайте и укажите лишнее слово в логическом ряду.**

Сатучы, тегүче, укытучы, тәрбияче, укучы.

**4. Прослушайте и укажите, что изменено во втором предложении каждой пары.**

1) Ул укыта. Ул мәктәптә укыта.
2) Ул ашамлыклар сата. Ул кибеттә ашамлыклар сата.

3) Ул йортлар төзи. Ул шәһәрдә йортлар төзи.
4) Ул чәчәкләр үстерә. Ул бакчада чәчәкләр үстерә.

**25–26 нчы дәресләр**

**1. Прослушайте и измените предложения по образцу.**
Образец: *Мин мәктәпкә барам. – Мин мәктәпкә бармыйм.*
Мин иртә торам. – ... .
Мин зарядка ясыйм. – ... .
Мин салкын су белән юынам. – ... .

**2. Прослушайте и укажите слова со звуком [ү].**
Сигезенче, дүртенче, өченче, үзем, сәгать, түгел.

**3. Прослушайте и укажите слова с твёрдыми гласными звуками.**
Беренче, икенче, өченче, дүртенче, бишенче, алтынчы, җиденче, сигезенче, тугызынчы, унынчы.

**4. Прослушайте и измените словосочетания по образцу.**
Образец: сәгать биш – сәгать биштә.
сәгать өч – ... .
сәгать җиде – ... .
сәгать ун – ... .
сәгать унике – ... .

**5. Прослушайте и перескажите содержание.**
Мин иртән тордым. Юындым. Урынны җыйдым. Иртәнге ашны ашадым. Сәгать җидедә мәктәпкә киттем.

**27–29 нчы дәресләр**

**1. Прослушайте и скажите, как изменились бы глаголы, если бы эти действия не происходили.**
Булышты, җыештырды, сипте, үтүкләде, әзерләде, ашады.

**2. Прослушайте и укажите слова, отвечающие на вопрос *нишләми*?**
Тора, тормый, эшли, язмый, сөйләми, үтүкли, себерә, сөртми, юмый.

**3. Прослушайте и укажите лишнее слово в логическом ряду.**

Чыгара, әзерли, ашый, карый, юды, сөртә, себерә.

**4. Прослушайте и укажите, что добавлено во втором предложении каждой пары.**

1) Юа. – Идән юа.
2) Үтүкли. – Кер үтүкли.
3) Себерә. – Идән себерә.
4) Әзерли. – Ашарга әзерли.
5) Сөртә. – Тузан сөртә.

**5. Прослушайте и измените слова по образцу.**

Образец: юа – юды.

Сөртә, уйный, чыгара, суырта, әзерли, карый, себерә.

**6. Прослушайте и измените слова по образцу.**

Образец: мин булыштым – син булыштың – син булыштыңмы?

Мин юдым.
Мин сөрттем.
Мин суырттым.
Мин үтүкләдем.
Мин әзерләдем.

**7. Прослушайте и перескажите содержание.**

Мин бүген өйне җыештырдым. Идәнне чиста итеп юдым. Гөлләргә су сиптем. Тузан сөрттем. Әни кайтуга ашарга пешердем.

## 30–33 нче дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова с мягким произношением.**

Иртән, озак, юына, өстәл, каймак, тәмле, әзерли, чәй, һәрвакыт, тәлинкә, кашык.

**2. Прослушайте и укажите лишнее слово в логическом ряду.**

Кашык, тәлинкә, чәнечке, чәй, пычак.

**3. Прослушайте и укажите, что добавлено во втором предложении каждой пары.**

1) Мин урын-җирне җыям. Мин урын-җирне үзем җыям.
2) Мин иртә тордым. Мин бик иртә тордым.
3) Мин әнигә булыштым. Мин бүген әнигә булыштым.

**4. Прослушайте диалог и перескажите его содержание.**

– Син әниеңә булышасыңмы?
– Әйе, мин әнигә һәрвакыт булышам.
– Өйдә идән юасыңмы?
– Әйе, идән юам, тузан сөртәм.
– Ә әниеңә кухняда булышасыңмы?
– Әйе, мин ипи кисәм, өстәлгә кашыклар, тәлинкәләр куям.

**5. Прослушайте и укажите слова, отвечающие на вопрос *нинди*?**

Эшчән, ихтирамлы, ялкау, кирәк, җыештыра, тырыш, әйбәт, начар, әзерли.

**6. Прослушайте и закончите предложения.**

1) Илнур – тырыш малай, чөнки ... .
2) Рәсим ялкау малай, чөнки … .

## 34–37 нче дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова со звуком [ө]**.

Мөмкин, еш, су, ярый, кич, өй, иртән, гөл, озак, ярый, кирәк.

**2. Прослушайте и измените словосочетания по образцу.**

О б р а з е ц : аш пешерә – аш пешерергә кирәк.
Өй җыештыра.
Кер үтүкли.
Әнигә булыша.
Чүп чыгара.
Идән себерә.
Кибеткә бара.

**3. Прослушайте и укажите, что изменено во втором предложении каждой пары.**

1) Мин әниемә һәрвакыт булышам. Әниемә булышырга кирәк.
2) Алсу гөлләргә су сибә. Гөлләргә су сибәргә кирәк.
3) Әни савыт-сабаларны юа. Савыт-сабаларны юарга кирәк.

**4. Прослушайте диалог. Выберите реплику, выражающую похвалу.**

– Әни, мин гөлләргә су сиптем.
– ... .

1) Шулаймы?
2) Рәхмәт. Бик яхшы булган!
3) Кайчан?
4) Менә булдыргансың!

**5. Прослушайте и закончите предложения, используя инфинитивную форму глагола.**

1) Наиләгә тузан … .
2) Ләйләгә гөлләргә … .
3) Балаларга кичке ашны … .

## 38–41 нче дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова со звуком [э].**

Минемчә, билгеле, беренчедән, синеңчә, җиңел, быел.

**2. Прослушайте и укажите слова со звуком [ķ].**

Кыз, рәсем, китап, кухня, чәй, бик, кыстыбый.

**3. Прослушайте и укажите лишнее слово в логическом ряду.**

Өчпочмак, чәкчәк, бәлеш, пирожный, кыстыбый.

**4. Прослушайте и укажите слова, обозначающие действие.**

Пешерә, укый, ярдәм итә, эчә, тату, күңелле, чакыра.

**5. Прослушайте и укажите, что изменено во втором предложении каждой пары.**

1) Әни пирожный пешерә. Әни чәкчәк пешерә.
2) Бергә чәй эчү күңелле. Бергә чәй эчү күңелсез.
3) Оля китап укый. Оля рәсем ясый.

